СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫ ИҖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

29 октябрь, 1997ел.
ЧӘРШӘМБЕ

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. № 122 (8134) Бәясе билгеләнгәнчә

# КӨЗ АШЫКТЫРА: СОҢГЫ ЭШЛӘРНЕ ОЧЛЫЙК!

## Һәр нәрсәнең җае бар

ФОТОРЕПОРТАЖ

«Тәрнәс»леләр быел дәүләткә шикәр чөгендере сату буенча килешү йөкләмәсен районда иң беренче булып тутырдылар. Бүгенге көнгә бу хуҗалыктан заводка _1250 тоннадан күбрәк чимал килде инде, һәм әле чөгендер сату дәвам итә. Чималның сыйфаты да әйбәт.

Хуҗалыкның чөгендер кырына барып чыккач, иң элек анда чөгендер чистартучы хатын - кызлар азлыкка игътибар иткән идек. Югыйсә, биредә француз технологиясе дә кулланылмый бит, гомумән, хуҗалыкта чөгендерне сату өчен игә башлауларына да берничә генә ел. Баксаң, әллә ни катлаулы сере юк икән моның. Үзләрендә андый чәчкеч булмагач, күрше Кузнецов исемендәге хуҗалыкка мөрәҗәгать иткәннәр һәм теләрнең сыйфатлы итеп чәчеп бирүләренә әле дә мең рәхмәт укыйлар. Ә инде шуннан соң рәт арасын эшкәртү, ашлама кертү кебек эшләрнең барысын да Евгений Иванович Черевов (рәсемдә уңда) башкарган. Җиренә җиткереп эшләгәнлеге күз алдында - чөгендерләр эре. Монда инде Норлаттан ярдәмгә килгән икенче мәктәп коллективының да хезмәте зур. Чималны заводка чиста да иттереп озатуга исә чөгендер казуга техниканы тулы комплекста алып чыгу нәтиҗәсендә ирешәләр икән. Рәсемдә күренгәнчә, буразнага бер - бер артлы яфрак ургыч, өстәмә чистарткыч һәм казу комбайны төшә. Беренчесен Александр Аленин (уртада) эшләтсә, икенчесендә - Евгений Иванович. КС - 6 комбайнындагы Вячеслав Христофоровны да (сулда) мактап туя алмыйлар хуҗалыкта. Ул казыткан чөгендерне «Беларусь»тагылар Александр Горшков (сулдан икенче) белән Иван Захаров (уңнан икенче) ташып торалар.





Үзләре дә, техникалары да бу рәсемгә кермәгән тагын ике кешенең уртак уңышта хезмәт өлеше саллы. Сергей Курганаев белән Фәрит Әхмәдиев чөгендер төягечләрне эшләтәләр. Казылган чөгендер төягеч аша ике кат үткәрелә монда һәм шуңа күрә бермә - бер чистарып кала да. Эшче кулларга кытлык кичергән хуҗалыкта моны сы кыен хәлдән чыгуның әлегә мөмкин булган үзенә бер юлы. Һәр нәрсәнең җае бар шул.

**Р.МУЛЛИН.**

**Н.АЗИЗОВ фотолары.**

## СОҢГЫ ГЕКТАРЛАРДА

**«Рассвет» КХАсы.** Хуҗалык кыр эшләрен соңгы гектарларда алып бара. Бу көннәрдә рассветлылар 180 гектарда татлы тамыр алуны төгәлләделәр. Чөгендернең 80 процентына якынын француз комбайны белән Касыйм Сатдаров чыгартты, КС - 6 комбайнында аңа ярдәмгә килгән Минталип Гобәйдуллинның булышлыгы да бик урынлы булды. Казылган чөгендерне чистартуда Гөлсем Сатдарова җитәкчелегендәге 18 хатын - кыздан торган звено шулай ук бик җитез һәм сыйфатлы эшләде. Бүген - иртәгә хуҗалык татлы тамыр сату планын үтәргә тора. Сүз уңаеннан, хуҗалык чималны кабул итү пунктына тулысынча диярлек үз көче белән ташыды. Төягечтә эшләүче Минсәлим Галимов та, шоферлар Илгиз Тимербулатов, Илгиз Хөсәенов, Фаяз Әхмәтвәлиев, Исламнур Мәҗитов бу эштә һич тоткарлык тудырмадылар.

144 гектарлы бөртеккә игелә торган кукуруз кырлары да тулысынча диярлек бушады. Кукурузны чәчү, тәрбияләү эшләрен башкарган Наил Бикиев үз эшенә бик тә намуслы караган булган: кырлар патшасы бер дигән итеп үсте, гектарыннан 90шар центнер уңыш бирде. Аның өлгереш дәрәҗәсе дә әйбәт: дымлылыгы 32 процентган артмый. Хуҗалыкта кукуруз җыюда МТСның өч «Кейс»ы эшләде, егетләр эшенә шулай ук мактаудан кала сүз әйтерлек түгел.

Кукуруздан бушаган җирләргә шунда ук туңга сөрү техникасы керә. Илшат Хөсәенов К - 700, ике Валерий - Максимов һәм Сенцов басуларны бер дигән итеп эшкәртеп калдыралар.

Шулай КХАда һәр эш комплекслы һәм оешкан төстә алып барылганга вакытында һәм сыйфатлы төгәлләнә, игенче кышка тыныч күңел белән керә.

**С.НУРУЛЛИНА.**

### Район хакимиятендә

## Начар юлда һәлакәтләр дә күбрәк

***Район хакимиятендә автотранспортчылар бәйрәме алдыннан үткәрелгән киңәшмәгә транспорт, юл төзелеше, күптармаклы производство предприятиеләре җитәкчеләре һәм ДАИ хезмәткәрләре чакырылган иде. Анда юлларда хәрәкәт куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча үткәрелергә тиешле чаралар турында сүз алып барылды.***

Киңәшмәне башлап сүз алучы ДАИ начальнигы Х.Әюпов катнашучыларны районда юл-транспорт һәлакәтләренең гомуми хәле белән таныштырды һәм быелгы чорның күңелсез саннарын китерде: юллардагы фаҗигаларның 80 проценттан артыграгы автотранспортчылар өлешенә туры килә. Быел районда 31 юл-транспорт һәлакәте теркәлгән, шуларда 8 кеше һәлак була, 26 сы тән җәрәхәтләре ала. Юл кагыйдәләрен бозу очраклары 10 меңгә җитә. Районда шул ук санда транспорт берәмлеге булуын исәпкә алсак, һәр транспортка бер очрак туры килә. Тизлекне арттыру, исерек хәлдә идарә итү, ә кайвакыт җәяүлеләрнең игътибарсызлыгы аркасында (бигрәк тә балалар) -ДАИ начальнигы фикеренчә, юлда һәлакәтләрнең төп сәбәпләре шулар. Хәер, еш кына автотранспортчылар гаебе түгел, ә юлларның, аеруча шәһәр эчендә начар хәлдә булуы, тиешле урыннарда юл билгеләре юклыгы да аяныч хәлгә китерә. Һәр 3нче һәлакәтнең Норлатта теркәлүе нәкъ шул хакта сөйли дә. Алда кыш, юлда йөрүне тагын да кыенлаштыра, куркыныч арттыра торган чор, МПП, юл төзү оешмалары юлларны үзвакытында чистартырга тиешле дәрәҗәдә әзерләнгәнме, юл-транспорт фаҗигаләреннән, юл өзеклегеннән саклану өчен чаралар күрелгәнме? Алга таба сүз шул хакта куерды һәм җитәкчеләр чыгышларыннан аңлашылганча, шәһәр эчендә юлларны төзекләндерү, чистарту, юл билгеләре урнаштыру һәм башкаларны үтәү буенча әлегә бердәм системалы чаралар эшләнмәгәнлеге ачыкланды: юл төзү оешмалары, шәһәр эчендәге юлларның МПП балансына күчүе сәбәпле, юлларның торышы өчен бары тик көнкүрешчеләр генә җаваплы дип килсә, соңгылары аларны башкару безнең генә хәлдән килмәячәк дип аңлата. Йомгаклап сүз алган шәһәр җирле үзидарә советы рәисе Р.Билалов та нәкъ шул соңгы фикерне куәтләде һәм шәһәр эчендә сыйфатлы, меңәрләгән транспортны күтәрерлек юллар салу матди яктан ничек кенә авыр булмасын, ДРСУ, НУАД кебек юл төзү оешмалары тарафыннан гына башкарылырга тиешлеген дәлилләде.

## Психологлармы? Күп кирәк

Идеологик ориентирлар ачык булмаган бүгенге көндә һәр мәктәпне, тәрбия бирү учреждениесен психологлар белән тәэмин итү - мәгариф учреждениеләре алдында торган мөһим бурычларның берсе булып кала бирә. Районда психологлар хәзерләү буенча ике еллык курслар да шул җәһәттән оештырылган иде. Районыбызның 12 укытучысы һәм тәрбиячесе өчен быелгы уку елы белем алуның икенче елы. Бу көннәрдә дә булачак психологлар шәкертләре - Казан дәүләт педагогия университеты педагог - галимнәре лекцияләрен тыңлап, белем эстәүләрен дәвам итәләр.

**Р.МИНАПОВА.**

### Рәсми хроника

## Рәис алышынды

23 октябрь көнне «Комбайн» КХАсы әгъзаларының гомуми җыелышы булды. Җыелыш шәхси гаризасы нигезендә хуҗалык рәисе Ә.В.Мөлековны вазифаларыннан азат итте. «Комбайн» КХАсы рәисе итеп моңарчы Әлки районы «Сельхозтехника» берләшмәсе управляющие урынбасары булып эшләгән Дамир Вакиф улы Фәссахов сайланды.

### *Хөрмәтле дуслар!*

**1998 елның беренче яртыеллыгына газетага язылу бара. Язылу бәясе ярты елга 26.400, өч айга - 13.200, бер айга - 4.400 сум.**

**Район газетасына язылырга ашыгыгыз! Ул һәрвакыттагыча сезгә яңалыклар, хәбәрләр, кызыклы киңәшләр белән бергә атналык телетапшырулар программасын да даими биреп барачак.**

# Ведомстводан тыш сак бүлегенә 45 ел

## ЫШАНЫЧЛЫ САКТА



**1964 нче елның 1нче ноябрендә ТАССРның җәмәгатьчелек тәртибен саклау Министры приказы буенча халык хуҗалыгы объектларын саклауны көчәйтү максатында Октябрь районы үзәге Норлатта ведомстводан тыш сак бүлекчәсе оеша.1983 нче елда аның начальнигы вазифасы элек район эчке эшләр бүлегенең политик тәрбия эше буенча начальник урынбасары вазифасын башкаручы Надыйр Нәгыйм улы Вәлиевка йөкләнә.Аның җитәкчелегендә бүлекчә киңәя һәм 1994 елда аерым бүлеккә әйләнә.**

**Н.Н.Вәлиев тумышы белән Октябрь районының Көрнәле Әмзә авылыннан.Аңлы тормышы милициядә,халык тынычлыгы һәм дәүләт байлыгы сагында үтә.Эшчәнлегендә ирешкән уңышлары өчен күп тапкырлар Республика ведомстводан тыш сак идарәсе тарафыннан бүләкләнә,РФ Эчке эшләр министрлыгы Мактау грамотасына лаек була.Өч ел элек погоннарын ике йолдызлы подполковник погоннарына алмаштыра.**

**Бүген юбилей уңаеннан Н.Вәлиевның газетадагы чыгышы бүлекнең тарихы, башкарылган эшләре,мактаулы кешеләре, киләчәккә планнары һәм башкалар турында барачак.**

Ведомстводан тыш сак бүлекчәсе оешкан елларда коллектив бик кечкенә шуңа да аның тарафыннан саклана торган халык объектлары да санаулы гына иде.Шуңа карамастан,1977 елга,Аксубай районында бүлек оешканчыга кадәр анда да халык байлыгын саклауны безнең бүлек тәэмин итте.1983 нче елда бездә аттестацияле состав 14 кешедән торса,быел аларга тагын 37 милиционер өстәлде. Бүгенге көндә алар шәһәр эчендәге объектларда,Төрнәс спирт заводында һәм 6 кеше Чирмешән районында хезмәт күрсәтәләр. 1987 елда үзәкләштерелгән күзәтү пульты барлыкка килүе,ягъни объектлар саклауда техник чаралар кертә башлау бүлекнең үсешенә зур этәргеч булды. Хәзергесе көндә безнең сак астындагы объектларның һәркайсы бүлек тарафыннан янгын сагы чаралары белән җиһазландырылды,объектларның 75 проценты үзәкләштерелгән пульт аша саклана.Соңгысын сакның иң ышанычлысы һәм арзан төре дип исәплибез.Шуңа күрә объектларда югары сиземле «Астра» аппаратлар урнаштырабыз. Бүгенге көндә яңа төрдәге «Астра» күләмле хәбәр бирүче аппаратлары куюны үзалдыбызга бурыч итеп алдык,чөнки соңгы еллардагы исәпләүләребез буенча да техник чаралар куллану нәтиҗәсендә ел саен 15-20 шәр урлау очрагы күзәтелә.149 очрак вак урлаучылар ачыкланды,бу сан да былтыргы шул чордан 18,2 процентка артыграк.20 урлауга әзерлек факты беленде.

Шулай итеп эчке эшләр органнарында ведомстводан тыш сак бүлеген үстерү концепциясен үтәү һәм ТР да җинаятьчелек белән көрәш буенча комплексла дәүләт программасы чараларын тормышка ашыру йөзеннән безнең бүлек тарафыннан 1997 елның 9 аена комплекслы,профилактик һәм башка чаралар күпләп үткәрелде. Нәтиҗәдә позитив күрсәткечләргә ирешелде.

Ведомстводан тыш сак бүлеге милекчеләр объектларын саклау турында 48 килешү төзеде,барлыгы 130 объект һәм аерым биналар саклана.Бүлек хезмәткәрләре матди байлыклар гына саклап калмыйча, җинаятьләрне ачу белән дә шөгыльләнәләр, хезмәтсез керем табучылар белән көрәшәләр, шәһәр һәм район җәмәгатьчелеге арасында тәртип булдыруда катнашалар.Агымдагы елда ведомстводан тыш сак бүлеге тарафыннан 8 җинаять ачылды,572 административ тәртип бозулар ачыкланды.Бу былтыргы шул чордан 71 гә күбрәк.

Елдан-ел уңышка ирешүебезнең төп сәбәбе кадрлар белән эшләүнең бик тирән һәм уйланылган итеп куелуыннан дип әйтергә кирәк. Бүлек җитәкчелеге нәкъ шул юнәлештә зур көч куя.Бүгенге көндә бүлектә 155 хезмәткәр эшли,шуларның 51е аттестацияле состав,ягъни формалы хезмәткәрләр,ә калганнары ирекле ялланучы хезмәткәрләр.Алар арасында бүлеккә озак еллар буе бөтен көчен,тырышлыгын биргән фидакарь кешеләр шактый.Милиция капитаны А.И.Логинов 22 ел өлкән инспектор вазифасын башкара,хезмәт бурычын намуслы итеп үти,мотовзвод командиры И.М.Туктаров,ПЦО начальнигы А.Н.Трофимов,ПЦО дежурлары К.В.Исмәгыйлов,К.Ш.Фәткуллин,Г.Е.Трубкин,тоткарлау группасы өлкән хезмәткәрләре И.Н.Вәлиев, А.С.Сәйфиев милиционер-шоферлар Х.С.Сәгъдиев, О.П.Ярунгин,Р.Р.Кәлимуллин,милиционерлар Г.Иванов,С.Алмазов, О.И.Анжаков, А.М.Алиев,взвод командиры ярдәмчесе В.Ф.Яллин һәм башкалар һәммәсе мактауга лаеклы кешеләр.Аларның киләчәктә дә үз бурычларын намус белән үтәячәкләренә,матди байлыкларны ышанычлы саклауларына шик юк.Бу җәһәттән,бүлектә эшләп үзләре турында якты истәлек калдырган ветераннарны да җылы сүз белән искә аласы килә.Алар А.Г.Баһманов, Н.И.Тиманкин, П.И.Янгильдин,Н.Минегулов,А.М.Алексашкин, А.Г.Куликов, Ю.Ф. Кузьмина, Е.Я. Яковлева, Е.Я.Исламгулова,В.В.Маликов,К.А.Садовникова, Н.В. Дорожкин,А.Г.Вәлиәхмәтова, Н.Г.Рәҗәпова, О.И.Яллина һәм башкалар тормышларының иң якты елларын авыр хезмәткә бирделәр.

Коллегаларны һәркайсын профессиональ бәйрәмебез белән котлап киләчәктә дә эшләрендә уңышлар, шәхси бәхет телим.

### КЫСКАЧА

**Элекке елларда республикада ведомстводан тыш сак бүлекләре арасында ярышларда призлы урыннар яулап килгән норлатлылар бүген дә сынатмыйлар. 1996 елгы күрсәткечләр буенча алар республикада өченче урынга лаек булдылар.**

***

**Бүлек киләчәктә эшчәнлек планын киңәйтергә ниятли:объектларны саклау, җинаятьчене тоткарлаудан тыш йөкләрне, кыйммәтле кәгазьләрне озату, гаражларга,фатирларга автоном сигнализация кую һәм башкаларны башкару күздә тотыла.**

***

**Бүлек хезмәткәрләре республика күләмендә үткәрелгән конкурсларда,спорт ярышларында катнашалар.1995 елда Җиңүнең 50 еллыгына багышланган концертта милиция өлкән сержанты Радик Хөсәеновның талантлы җырлавы югары бәяләнде: ул дипломант исемен алып кайтты.**

***

**Эчке Эшләр Министрлыгының ведомстводан тыш сак идарәсе 45 еллык юбилеен зурлап үткәрергә исәпли. Бәйрәмнең тантаналы өлеше Г.Камал исемендәге театрда башланып, «Акчарлак» ресторанында дәвам итәчәк. Ә аны хәтердә озак саклау максаты белән идарә махсус символикалы сәгатьләр чыгара һәм хезмәт уставын бозу очрагы булмаган хезмәттәшләренә тарата. Норлат сакчыларының һәммәсе диярлек шул сәгатьне тагып йөриячәк.**

### КЫСКАЧА

# Өлгерергә һәм тоткарларга



Каракны ачыклау бер,ә аны тоткарлау сак органы хезмәткәрләреннән икеләтә җаваплылык һәм чыдамлылык таләп итә. Ведомстводан тыш сак бүлегенең тоткарлау группасы тәүлекнең теләсә кайсы вакытында җылы урыннарыннан торып сигнал килгән объектка санаулы минутларда килеп җитәргә әзер.Алар җилкәсендә күпьеллык тәҗрибә тупланган,нәкъ шул иң катлаулы ситуациядә ярдәмгә килә дә.Саклана торган объектка үтеп керергә һәм җиңеллек белән баерга тырышучы җинаятьчеләр белән күпме тапкыр күзгә-күз очрашырга туры килә аларга.Шунысын әйтергә кирәк:мондый «көрешүләр» угры файдасына булмый.Бер генә мисал:1996 елның 10 декабрендә төнге сәгать 1 тулып 45 минут узгач гастрономда сигнал эшләве турында хәбәр килә.ПЦО дежуры,милиция өлкән лейтенанты Г.Е.Трубкин,шофер-милиционер Х.С.Сәгъдиев,мотовзвод милиционеры Р.И.Кәлимуллин,стажер А.Дмитриев составындагы «ПА-552» экипажы объектка 2 минутта килеп җитә.Объектны тикшергәннән соң ишектә йозак юклыгын күрәләр.Бүлек тарафыннан сакланылмый торган «Детский мир» кибете ягыннан баскыч мәйданчыгында аяк тавышлары ишетелә.Ишек төбендә кибеттән чыгарылган матди байлыкларга тап булалар,засадага кереп каракларның төшкәнен көтәләр һәм тегеләре шул кармакка эләгәләр дә.Җинаять юлына басучыларның берсенә 18,икенчесенә 20 яшь була.Мондый мисалларны тагын да китерергә булыр иде.

Бүген группа җинаятьчеләрне тоткарлауга дүрт аяклы дусларын да катнаштыра башлады.Группада 2 егет Хәлим Сәгъдиев һәм Айрат Сәйфиев (Казан егете) Казанга барып немец овчаркалары алып кайттылар һәм аларны уңышлы гына тәрбиялиләр дә.Фотохәбәрчебез Наил Азизов тоткарлау группасын - милиция өлкән сержанты И.Н.Вәлиев, өлкән сержант Х.С.Сәгъдиев, милиция сержанты А.С.Сәйфиевны дусты белән һәм Г.Е.Трубкинны ведомстводан тыш сак бүлеге бинасы янында төшереп алды.

### Эре план белән

# Кан һәрчак кирәк



Бүген күп нәрсәнең кыйммәте югалды. Акча. Кешеләр арасындагы аралашу нормасы. Ә кан? Ул һәрчак кирәк иде: авариягә очраган, җинаятьче пычагы астына эләккән яисә катлаулы операциядә булучыларга салдылар аны. Бүген кан бирү, икенче төрле итеп әйткәндә донорлык компаниясе ничек тора?

Кан алу район станциясендә иң «кайнар» көн - сишәмбе. Донорлардан канны нәкъ менә шул көнне алалар. Бу сишәмбедә алар 10 кеше иде. Шуның берсе - хатын - кыз. Азмы? Кан тапшырырга теләүчеләр, мөгаен, күбрәк тә булыр иде. Әмма кайберәүләрне алдан үткәрелә торган мәҗбүри процедуралар «куркыта». Дәүләт санэпидкүзәтү үзәгендә булырга, наркологка күренергә, дермотолог, участок терапевты янына керергә, флюорография һәм туберкулез кабинетларыннан белешмә алып килергә, хатын - кызларга исә тагын гинекологка да барырга кирәк... Элегрәк бу процедура сизелерлек гади иде. Бу катгый таләпләр менә инде берничә ай гамәлдә. Һәм әйтергә кирәк, алар төгәл үтәлә: кан белән шаярырга ярамый - начары зур бәлага китерергә мөмкин... Шунысын да әйтергә кирәк, кан тапшырырга теләүчеләр бу таләпләрне аңлап кабул итәләр һәм бары тик системаның бер тапкыр куллану - кулланмавы белән генә кызыксыналар.

Ә аның белән бергә тулы тәртип: кан алу системасы японнарныкы һәм бары бер тапкыр гына файдаланыла. Донор каны шунда ук гемаконнарга тутырыла. Алары да Япониядән кайтартылган. Кан төгәл үлчәүләрдә үлчәнә һәм асылмалы хәлдә саклауга суыткычларга озатыла. Температура да үзенчәлекле монда: кан өчен + 4 - 5 градус, плазма өчен - 30 градус. Нигездә, кан тапшыру күп вакытны алмый. Моның өчен 5 - 10 минут кына кирәк. Һәр донор белешмәләрдән тыш паспортын да күрсәтергә тиеш: Азербайҗан, Таҗикстан, Азия һәм Африка илләре малярия буенча ышанычсыз дип санала. Шунда ук лаборантка Галина Чумакова кан группасы, резус фактор, гемоглабинның күпмелеген ачыклауга анализ ала. Донор каны тагын СПИД, гепатит, сифилиска да тикшерелә. Кан бирергә килүчеләрнең барысын да врач - терапевт Виктор Хәйретдинович Гыйбадуллин карый: кан басымын, пульс, температурасын үлчи, карточка тутыра... Һәр кешегә 1 стакан ширбәтле чәй һәм печенье бирелә. Канын тапшыргач ике көнлек ялга хокук бирүче белешмә дә ала. Сүз уңаенда шуны әйтергә кирәк, белешмә ел дәвамында гамәлдә кала.

Быел кан алу станциясе аркылы 700 донор үтте - бер өлеше билгеле инде 2, 3 тапкыр. Кагыйдә буенча донор канны икенче кат 56 көннән бирергә мөмкин.

Канның минималь дозасы 375, максималь дозасы 475 грамм. Күпләр бирегә акча өчен килә: беренче доза өчен район үзәк шифаханәсе кассасыннан сезгә 95 мең, икенчесе өчен 115 мең сум бирәчәкләр. Бүгенге тормыш кыйммәтчелеге заманасында, турысын әйтик, әлеге сумма белән әлләни ерак китеп булмый. Әмма кемдер өчен бу акча «тишек» гаилә кесәсенә җитди ярдәм. Бирегә чиратта торучы 30 яшьлек бер хатын - кыз - донор сөйләде: бу акчалар гаиләбез өчен зур ярдәм: ирем күптән хезмәт хакы алмый, ә үзенең кан тапшырып алган 100 меңен эчеп бетерде... Хезмәт хакым бик аз, балалар бакчасы өчен взнос түләргә кирәк. Ике баланы ашату - киендерүгә дә күпме китә...

Станция шәфкать туташы Нина Огонева донорларның күпчелеген күреп белә. Нигездә алар ир - атлар. Яшьләре 40ка кадәр. Байтагы эшсезләр. Чиратта үзләрен тыныч тоталар, медицина персоналына бик игътибарлы булырга туры килә. Шулай берчак ике егет килгәннәр иде, исемлек буенча тикшерсәләр алар наркоманнар буларак учетта торалар икән. Гепатит, венерик авырулар, туберкулез белән авырганнардан, 60тан өлкән яисә 18 яшьтән кече булганнардан да кан алмыйлар. Ә менә күрше районнардан килүчеләрдән канны проблемасыз алалар. Күтәмәдән 27 яшьлек егет килгән иде (Чирмешән районында шундый донор пункты юк): «Бәлки минем каным да кемгә булса да кирәк булып чыгар,» - дип. Билгеле инде, канын алдылар - ул һичшиксез кирәк булачак.

Канның төрлесе кирәк: реанимация яисә иртәгә, мисал өчен, тудыру бүлегенә ниндие кирәк буласын алдан фаразлап буламы? Ашыгыч очракка станциядә «үз» система эшләнгән: канны авыруның туганнарыннан, медицина работникларыннан яисә озак еллар донор булып торучылардан алалар: «Ашыгыч ярдәм» станциясенә шалтыраталар да адресны әйтәләр. Станция хезмәткәрләре үзләре исә һәрвакыт әзер: чиратлап атналап кизүгә китәләр.

Донорлардан алынган кан номерлы һәм аны икенче доза белән һичкайчан бутамыйсың. Гемаконнарга төрле тестәге - кан группасы буенча биркалар ябыштырыла. О (1) һәм А (II) каны (уңай резуслы) аеруча еш кирәк була. Кире резуслы кан һәрвакыт дефицитлар разрядыннан.

Кан алу станциясенә донор каны сорап үзәк шифаханә бүлекчәләреннән генә түгел, участок шифаханәләреннән дә мөрәҗәгать итәләр. Аны Казанда да көтәләр - узган айда республика кан салу станциясенә 12 литрдан артык кан озатылды. Шуның 5 литры консервацияләнгән, медицина препаратлары ясау өчен кулланыла торганы иде. Безнең станциядә исә кан 35 көнгә кадәр саклана ала, плазма саклау срогы 3 айгача. Сүз уңаенда шуны да әйтергә кирәк, әгәр дә станциянең үз центрифугасы да булса, плазма алу параметрлары сизелерлек үзгәрер иде. Туңдырылган килеш ул бер ел саклана ала.

Кан һәм аның компонентлары шифаханәләргә һәрчак кирәк. Бу уңайдан район үзәк шифаханәсе табиблары ни уйлыйлар?

***В.Д.Тимофеева***, тудыру бүлеге мөдире:

- Безгә еш кына хатын - кызлар күренеп торган аз канлылык билгеләре белән киләләр. Соңгы вакытта аларның саны 3 тапкыр диярлек артты. Бала табу процессы авыр булганда да кан да, плазма да кирәк. Әмма без сыйфатлы канга һәм препаратларга мохтаҗлык кичерәбез - канны бары тик сау - сәламәт кешеләр генә бирергә тиеш.

***А.В.Слепцов***, хирургия бүлеге мөдире:

- Станциядә тикшерелгән кан булу без, хирурглар өчен зур ярдәм. Бүлеккә еш кына ашказаны - эчәк кан югалтулары белән киләләр - кан салмыйча мөмкин түгел. Әле менә бу көннәрдә генә язва авыруы приступы булып күп кан югалткан М.ны китерделәр. Кан запасы коткарды безне.

... Май аенда кан алу станциясе тарафыннан 40 литр, июльдә 37, август һәм сентябрьдә 25-әр литр кан кабул ителде. Ә донорларны биредә һәрвакыт көтәләр.

**Т.НАЗАРОВА.**

**Октябрь районында 40 почетлы донор яши. Алар 4 дистә тапкыр каннарын бушлай биргән кешеләр. Почетлы донорлар медицина учреждениеләрендә чиратсыз дәвалану, теш протезларын бушлай ясату һәм ремонтлату, рецептлар буенча дару средстволарын алу буенча льготалардан файдаланалар. Шулай ук бу категория кешеләрдән коммуналь хезмәтләр өчен түләү 50 процентка кимрәк алына.**



# КУЛЛАРЫ - РУЛЬДӘ, ҮЗЛӘРЕ - ЮЛДА

**Рәсемдәге әлеге егетләр - автотранспортчылар. Төрле коллективларда эшлиләр алар. Фәрхать Ибраһимов, Ринат Хәйретдинов һәм Рәхимҗан Галләмов - «Агрохимсервис» АҖе шоферлары. Алексей Киселев һәм Эдуард Хаҗетдинов - УТТ вәкилләре. Быелгы урак чорында алар МТСның «Кейс»лар җыелма отряды составында комбайннардан ашлык ташыдылар. Үзара дус - тату эшләделәр алар. Хезмәтләрендә дә сынатмадылар.**

**Рәсемдә: Ф.Ибраһимов, Р.Хәйретдинов, А.Киселев, Р.Галләмов, Э.Хаҗетдинов.**

# Безнең халык укырга ярата мы?




Норлатта төп мәгълүмат үзәге булып, билгеле ки, үзәк китапханә санала. Аның фондында төрле темага караган 80 меңнән күбрәк данә китап тупланган. Укучылар арасында мәктәп балалары, читтән торып укучы студентлар, укытучылар, пенсионерлар күпчелекне тәшкил итә. Абонемент бүлегендә бер китапка ике - өч кеше чират торган очраклар сирәк түгел, уку залында да, бигрәк тә ял көннәрендә кеше күп була. Килүчеләр яңа газет - журналларны караштырып чыгарга омтылалар, аларны һәм китапларны үзләренә төнге «абонементка» да алгалыйлар ( монда хезмәт күрсәтүнең андый төре дә бар).Күрәсең, күпсанлы телеканаллар да халыкның мәгълүматка булган ихтыяҗын канәгатьләндереп бетерә алмый икән.

Ә китапханәнең ул төр фонды ничегрәк тулыландырыла соң? Периодик басмаларга язылуга акча бүлгәндә властьлар китапханәне санга сугалармы?

-Билгеле, икътисадны реформалаштыру еллары безне дә читләтеп үтмәде,- ди үзәк китапханә системасы директоры Ольга Михайловна Венедиктова.- Алай да яздырып алына торган басмаларга дип акча бирелә безгә. Менә беренче яртыеллыкта безгә периодик басмаларга язылу өчен җирле бюджеттан 100 миллион, икенче яртыеллыкта 140 миллион сум акча бүлеп бирелде. Күрше районнар белән чагыштырганда бездә бу яктан хәл яхшырак.

Моннан тыш, Татарстан китап нәшрияты китапларын сатып алуга 7,5 миллион сум акча бирелгән иде һәм без шул акчага 1760 данә яңа китап алып кайттык. ТР Мәдәният министрлыгының үзәкләштерелгән средстволары исәбенә Казаннан бибколлектордан 1605, Милли китапханәдән 2864, барысы 18,5 миллион сумлык китап кайтты. Милли китапханә тагын берничә дистә китапны бүләк итеп тә бирде - укыгыз гына. Моннан тыш, китапханәчеләр төрле түләүле хезмәтләрдән кергән средстволар исәбенә үзләре тагын 730 мең сумлык китап сатып алдылар.

Китапханәдә фондны русча һәм татарча гына түгел, чувашча да китаплар белән тулыландырырга тырышалар. Әле менә Чуваш нәшриятына 10 миллион сум акча күчерелгән һәм ул китаплар озакламый кайтып җитәчәк.

... Бүген китапханәдә 3612 укучыга формуляр тутырылган. Ел ахырына кадәр ул сан һичсүзсез ишәячәк әле.

**Т.АЛЕКСЕЕВА.**

# 2 нче мәктәпкә - 60 яшь

Норлаттагы иң өлкән урта мәктәп булган 2 нче рус - татар мәктәп - гимназиясенә 60 ел тулды. Бай тари-



хы, данлы традицияләре булган бу гыйлем йортын төрле елларда тәмамлап чыккан кешеләр бүген илнең төрле почмакларында яшиләр һәм эшлиләр. Узган шимбә көн үткән юбилей тантанасына килүчеләр арасында да төрледән - төрле һөнәр ияләре байтак иде. Юбилейдан репортажны газетабызның алдагы саннарыннан берсендә күрерсез. Ә бу рәсемнәр - мәктәпнең алтмыш еллык тарихының аерым бер сәхифәләре генә.

Мәктәп бинасы 1936 елда салына башлый һәм инде икенче елны ук ул җиде классны укытып чыгара. 1940 елда беренче чыгарылыш була. Шулардан Надежда Михайловна Шувалова, Нина Николаевна Смирнова, Екатерина Александровна Елакова, Антонина Абрамовна Пестова бүген дә Норлатта яшиләр.

Бөек Ватан сугышы чорында мәктәп бинасына эвакогоспиталь урнаша. 1946 елда мәктәп яңа бинага күчә.

Ә менә бу рәсемдә - 1947 елда биредә беренче тапкыр урта белем турында аттестат алучылар. Аларның икесе инженер булып китә, калганнары барысы да укытучы һөнәрен сайлый.

Икенче рәттә басканнар (сулдан уңга): Валентина Нуждина, Александр Поляков, Зоя Першина, Вениамин Филимонов, Таисия Корнеева, Николай Макеев, Зинаида Миронова, Роза Герасимова, Лидия Рыбакова, Виктор Кистенев. Аларның онытылмас укытучылары Е.Т.Аброков, М.М.Антонова, Д.Ф.Герасимов, Ю.П.Васильева.

Икенче рәсемдә мәктәпнең 50 нче еллардагы педагогик коллективы сурәтләнгән. Утырганнар (сулдан уңга): И.И.Дәү-



ләтшин, Ф.М.Ситников (1958 -63 нче елларда директор), А.Ф.Лазарев (1953 - 56 елларда директор), В.И.Пермякова, В.М.Верин; басканнар: Ф.Х.Җомаголов, Е.Н.Дмитриева, Е.М.Муханова ( озак еллар буе завуч булып эшләгән), А.Я.Хөснетдинова, __, М.Г.Васин.

Мәктәптә төрле елларда директор булып Иван Петрович Шульдеев, Павел Петрович Захаров, Евгений Тихонович Аброков, Анастасия Антоновна Брагазина, Александр Федорович Лазарев, Федор Николаевич Давыдов, Фоат Мулланурович Ситников, Надежда Михайловна Шувалова, Николай Григорьевич Лапкин (22 ел!), Николай Тимофеевич Мыльников эшлиләр. Хәзер мәктәпне А.А.Евлентьев җитәкли.



Мәктәп бүген дә районда һәм шәһәрдә иң зурлардан. 45 класста 1207 бала укый, аларга 88 укытучы белем бирә. (Өченче рәсем). Өченче ел инде мәктәп рус - татар мәктәп гимназиясе статусын йөртә. Мәктәпне тәмамлаучыларның ел саен 30 - 40 проценты югары уку йортларына керә, мәктәпне медаль белән бетерүчеләр саны арта бара. Биредә укып чыгучылар арасында җитәкче урыннарда да, халык хуҗалыгына кирәкле башка һөнәрләр буенча да фидакарь хезмәт куючылар бик күп һәм педагогик коллектив алар белән чын - чынлап горурлана.

## Җәүдәт Камалов



# Кычытканлы авылы тарихыннан

**( Ахыры. Башы 119-121 саннарда).**

Иске Әлмәт базарында да чыгышлар ясый, листовкалар тарата. Бу эшчәнлеге белән ул кулакларның ачуын чик дәрәҗәдә кабарта.

Җиһангир Рәҗәповның авылда икәнен белеп, Кызыл гаскәрләр басымы астында, Норлат станциясе юнәлешендә чигенүче ак чехлар Әлмәттә тукталганны ишеткәч, ачулары кабарган Насыйбуллин Хәбибулла мулла, кулак Әхмәтшин Әхмәтҗан чехларны авылга чакырып записка белән Хәммәдиев Әхмәтвәлине Әлмәткә җибәрәләр.

Халкыбызның тугрылыклы улы якташыбыз Җиһангир Рәҗәпов сатлык җаннар аркасында ак цехлар кулыннан гаиләсе һәм анасы белән бергә һәлак була. Шакиров Шәрифулла әтисе Шакирҗан агай да алар белән бергә атыла.

Кызыллар авылга кергәннән соң Рәҗәповлар гаиләсенең атылуында гаепләп Хәммәдиев Әхмәтвәлине кулга алалар, Чистайга алып китеп аталар. Төп гаепле кеше Насыйбуллин Хәбибулла мулла 1929 елда репрессияләнә.

Бөек Ватан сугышында авылдашларның 160сы сугыш кырларында һәм алынган җәрәхәтләрдән соң кайтып тиздән башларын куйдылар. Хатын - кызлардан сугышка киткән Ильясова Фаизә дә әйләнеп кайта алмады.

1967 елның 4 ноябрендә Җиһангир Рәҗәповка һәм Бөек Ватан сугышында һәлак булган авылдашларга багышланган дүрт метрдан биек обелиск - һәйкәлне ачу тантанасы булды. Шунда бөтен авыл халкы җыйналды. Укучылар колоннасы байракларны алга иеп һәлак булучыларны хөрмәтләп уздылар.

Һәйкәл авторы Җ.К.Камалов, төзүчеләр Габбас Мостафин, Нәкыйф Могыйнов. Быел һәйкәл куелганга 30 ел тула.

# КОТЛЫЙБЫЗ!

Әхмәт авылында яшәүче кадерлебез **Нурхәмәт Хуҗәхмәт улы Хәйбуллинга** 71 яшь тула.

Яшәү маягы син безнең өчен,
Кешелегең белән үрнәк син.
Мең-мең рәхмәт тәрбияңә,әти,
Безнең өчен һәрчак кирәк син.

**Изге теләкләр белән тормыш иптәше,балалары һәм оныклары.**

# Белдерүләр

## Сатабыз

**Некрасовкада дача**.Адрес:Циолковский ур.,2.

***

**3 бүлмәле фатир**.Адрес:Московская ур.,5-45.

***

**1995 елгы ВАЗ-21063**.Адрес:К.Маркс ур.,2-28,16 сәг.тән соң.

***

**1992 елгы бик яхшы хәлдәге ВАЗ-2106.**
Адрес:Дружба ур.,66-53.

***

**Ретранслятор районында капиталь гараж**.Адрес:Ленинградская ур.,11-13 (СПТУ йорты) 18 сәг.тән «21.00сәг.кә кадәр.

***

**1991 елгы 18 мең км. юл үткән ГАЗ-66.** «Иверия» кибетенә мөрәҗәгать итәргә.

***

**«Москвич-412»,алып китү өчен металл гараж.**
Тел.: 5-23-17.

***

**Ашыгыч рәвештә йорт.Бәясе килешү буенча**.
Тел.: 5-12-32.

***

**Яшәү өчен әйбәт хәлдәге күчмә щитлы вагон,мәйданы-18 кв.м. Бәясе-килешү буенча**.Тел.: 5-21-22.

***

**1 бүлмәле фатир**.Тел.: 2-26-69, 17 сәгатьтән соң.

***

**Кулланышта булган «Свияга» суыткычы**.
Тел.: 2-12-71.

***

**1996 елгы ВАЗ-2106,двигателе-өчленеке; 3х5 метрлы мунча бурасы**.Адрес: Чаллы Башы,Төзүчеләр урамы,4-7, Егоров М.В. Тел.: (код 251) 9-16-39.

***

**Коттедж, газ белән җылытыла,башка коммуналь уңайлыклары,йорт яны корылмалары бар.**Адрес: Икенче Дачная ур., 16 (шикәрчеләр бистәсе).

***

**Иске заправка юлы буенда таш гараж.**
Адрес: Дачная ур.,21. Тел.: 65-0-73, Сөләйманов Н.И.

## Төрлесеннән

**Арзан һәм сыйфатлы итеп йортлар,гаражлар төзибез**.Тел.: 5-16-25,Нәҗип.

***

**Октябрь район кулланучылар җәмгыяте коопродторгына һөнәри белеме булган сатучылар кирәк.**
Адрес: Кооператив ур.,3. Тел.: 2-11-32, 2-12-66.

***

**Уңайлыклы йорт сатып алабыз яки Түбән Кама шәһәрендәге 3 бүлмәле фатирга алмаштырабыз.**Адрес:Гагарин ур., 12-15.

***

**Комплекты белән ат дирбияләрен он,шикәр,майга, консервланган ит продуктлары,карабодай,тозланган тирегә алыштырабыз.Башка тәкъдимнәр дә карала.** Түбән Камада тел.: 33-91-62,6 дан 19 сәг.кә кадәр, 33-92-33, 19 сәг.тән соң.

***

**1994 елның 18 маенда Каравыл Тавы урта мәктәбен тәмамлау турында Яковлев Юрий Валерьевич исеменә бирелгән 258997 номерлы аттестатны,югалу сәбәпле,гамәлдән чыккан дип исәпләргә.**


***Идел Буе региональ наркология үзәге***

*Алкогольгә бәйлелектән һәм тәмәке тартудан бер сеанста кодлаштыру.* ***Табиб М.Б.Багрянцев.***

**Бездә генә!**

**Тулы анонимлык. Индивидуаль якын килү. Дәвалау барышында пациентның туганнарына да катнашырга рөхсәт ителә. Белешмә бирелә. Консультация, әңгәмә, кодлаштырудан соң күзәтү һәм ярдәм - бушлай!**

**Язылу һәм әңгәмә дәвалау көнне, җомга көннәрендә, 7, 21ноябрьдә көндезге сәгать 2дә район мәдәният йорты бинасында уздырыла.**

РФ сәламәтлек саклау министрлыгыннан 1995 елның 16 гыйнварында бирелгән № 00164 - 30 лицензия.



БАШ МӨХӘРРИР **Р.Ф.ҖАМАЛИЕВ.**

МӨХӘРРИР **С.Н.ХӘЙРУЛЛИНА.**

Учредительләр: Октябрь район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.

"Дуслык" район газетасы атнаның чәршәмбе, җомга, шимбә көннәрендә чыга, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителә.

Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Норлат шәһәре, Карл Маркс урамы,19.

Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм җаваплы сәркәтип - 2-18-67, авыл хуҗалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар, хатлар һәм җәмәгать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-10-44, рус теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия,реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.

*Газета Татарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.*

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясе. Офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 2338 данә. 9417